**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары**
**2017-2018 уку елы. 7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты - 180 минут**
**максималь балл - 70**

## I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. Нечкә сузык авазлардан гына торган мәкальне билгеләгез. (2 балл)
   а) Тимерне кызуында сук, сүзне вакытында сөйлә.
   ә) Тал ком ярата, усак дым ярата.
   **б) Һәр ишеткәнен сөйләгән һич теләмәгәнен ишетер.**
   в) Гыйлем – ау, язу – бау.

2. Сузык авазларны белдерә торган хәрефләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)
   а) 39;
   ә) 12;
   б) 24;
   **в) 13.**

3. Мәкальдәге сингармонизмның рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)
   *Кәгазь – дәрья, каләм – көймә.*
   **а) дәрья;**
   ә) кәгазь, дәрья, каләм;
   б) кәгазь, каләм;
   в) дәрья, каләм.

4. Фразеологизмның татарча тәрҗемәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)
   ***Кот наплакал*** –
   а) арадан кара мәче үтү;
   **ә) энә очы хәтле;**
   б) тире дә сөяк кенә;
   в) балавыз сыгу.

5. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)
   *Мәскәү татары, шулай итеп, бу дәрестә безне **ормады**, **сукмады**, хәтта бер генә тапкыр ачулы сүз дә әйтмәде, шулай да җиңде.* (М.Мәһдиев)
   а) архаизмнар;
   ә) тарихи сүзләр;
   **б) синонимнар;**

в) антонимнар.

5. Мәкальдәге антоним сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Иртә уңмаган кич уңмас.* (Мәкаль)

**а) исемнәр;**

ә) вакыт рәвешләре;

б) киләчәк заман хикәя фигыльләр;

в) алмашлыклар.

6. Җөмләдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Биредә инде күп сыйлар өстенә тагын быелгы җир җиләгеннән кайнаткан кайнатма да һәм баллап катырган чәк-чәк тә бар иде.* (Ә.Еники)

а) быелгы, кайнатма, баллап, чәк-чәк;

**ә) өстенә, быелгы, җир җиләгеннән, кайнатма, баллап, чәк-чәк;**

б) быелгы, баллап, чәк-чәк;

в) өстенә, быелгы, кайнатма, баллап, чәк-чәк.

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән кисәкчәнең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Агачтан агачка кунып, “Кәк-күк!”, “Кәк-күк!” дип кычкыра торган күкене күргәнсез**дер**.* (Ф.Яруллин)

а) раслауны белдерә;

ә) чикләүне белдерә;

**б) икеләнүне белдерә;**

в) үтенүне белдерә.

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

***Чү**, бу ни хәл, бу ни эш?* (Ш.Галиев)

а) каршы куючы теркәгеч;

**ә) ымлык;**

б) модаль сүз;

в) чикләүне белдерә торган кисәкчә.

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

***Аның** дөнья зурлыгы бер мичкәсе **бар**, **бөтен** булган, буласы җилләрне **шул** мичкәдә ябып саклый икән, ди.* (Ф.Яруллин)

а) зат алмашлыгы, билгеләү алмашлыгы, билгеләү алмашлыгы, күрсәтү алмашлыгы;

ә) зат алмашлыгы, сорау алмашлыгы, билгеләү алмашлыгы, күрсәтү алмашлыгы;

б) зат алмашлыгы, боерык фигыль, билгеләү алмашлыгы, күрсәтү алмашлыгы;

**в) зат алмашлыгы, хәбәрлек сүз, билгеләү алмашлыгы, күрсәтү алмашлыгы.**

11. Э.Касыймов иҗатыннан тупланган мисаллар арасыннан тиңдәш кисәкләре булган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Матур ул Кызыл Яр!

ә) Еракта иксез-чиксез кара урман күренә.

**б) Барысы да шундый матур, шундый ямьле булып күренәләр.**

в) Кара-кучкыл чоңгыл өстендә балыклар уйный, түгәрәк-түгәрәк җитез алкалар йөгерешә.

12. Мәкальләр арасыннан кушма җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Инсафлының теле саф.

ә) Ана бала өчен төн йокысын өч бүлә.

б) Һәрбер сүзнең урыны бар.

**в) Уйлаган табар, уйламаган батар.**

## II. Башыгызны эшләтегез.

Тартык авазга башланган һәм тартык авазга тәмамланган сүзләрдән генә торган “Кышкы каникулда” дип аталган текст төзеп языгыз. Барлыгы 10 җөмлә һәм алар җәенке булсын. (10 балл)

## III.Теоретик бирем.

Оминимнар турында белгәннәрегезне языгыз, фикерегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. Омонимнар белән күчерелмә мәгънәле сүзләрнең охшаш һәм аермалы якларын билгеләгез. (10 балл)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Һөнәре бар ком өстендә көймә йөздерер*. (Мәкаль)

1. *Һөнәре* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (5 балл)
2. *Ком* сүзе кулланылган фразеологизмнар языгыз. (3 балл)
3. *Көймә* сүзен тартым белән төрләндерегез. (2 балл)
4. *Бар*, *өстендә, йөздерер* сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (6 балл)
5. Сез нинди кул эшләре беләсез? Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (10балл)

Текст язуга таләпләр:

- текст төзелеше ( башлам, төп өлеш, йомгаклау);
- җөмләләр дөрес, төзек булырга тиеш;
- язма телнең бай, сурәтле булуына игътибар итәргә;
- орфографик грамоталылыкка игътибарлы булырга.